**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О государственном имуществе Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
15 декабря 2022 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

1. Настоящий Закон регулирует отношения в сфере учета имущества, находящегося в собственности Республики Татарстан (далее – государственное имущество), управления и распоряжения государственным имуществом.

2. Действие настоящего Закона не распространяется на отношения, связанные с управлением и распоряжением землей, недрами и другими природными ресурсами, ценными бумагами (за исключением акций), находящимися в собственности Республики Татарстан, средствами бюджета Республики Татарстан, с приватизацией государственного имущества.

Статья 2. **Правовое регулирование отношений в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом**

Правовое регулирование отношений в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом осуществляется федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

Статья 3. **Полномочия Государственного Совета Республики Татарстан в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом**

К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом относятся:

1) законодательное регулирование отношений в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом;

2) осуществление контроля за соблюдением и исполнением законов Республики Татарстан в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом;

3) осуществление контроля за соблюдением установленного порядка распоряжения государственным имуществом;

4) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 4. **Полномочия Президента Республики Татарстан в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом**

К полномочиям Президента Республики Татарстан в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом относятся:

1) определение основных направлений государственной политики Республики Татарстан в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом;

2) утверждение перечня государственных унитарных предприятий Республики Татарстан, акционерных обществ, акции которых находятся в собственности Республики Татарстан, имеющих особо важное значение для экономики Республики Татарстан;

3) принятие в пределах компетенции решений об управлении и распоряжении государственным имуществом;

4) назначение, выдвижение для избрания, согласование назначения и выдвижения для избрания в случаях, установленных законодательством, представителей государства в органы управления и контроля хозяйственных обществ и товариществ, акции (доли) которых находятся в собственности Республики Татарстан, за исключением акционерных обществ, созданных в процессе приватизации, в отношении которых принято решение об использовании специального права («золотой акции») или о закреплении акций указанных обществ в собственности Республики Татарстан;

5) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 5. **Полномочия органов исполнительной власти Республики Татарстан в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом**

1. К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом относятся:

1) издание нормативных правовых актов во исполнение настоящего Закона;

2) утверждение государственных программ Республики Татарстан в сфере учета государственного имущества, управления и распоряжения государственным имуществом;

3) утверждение положения о реестре государственного имущества – Реестре государственной собственности Республики Татарстан (далее – Реестр);

4) определение органов исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющих полномочия в сфере управления и распоряжения государственным имуществом;

5) установление порядка определения размера арендной платы за государственное имущество;

6) утверждение перечней государственных унитарных предприятий Республики Татарстан и государственных учреждений Республики Татарстан, обеспечивающих осуществление органами государственной власти Республики Татарстан полномочий Республики Татарстан;

7) принятие решений:

а) о создании государственных унитарных предприятий Республики Татарстан, государственных учреждений Республики Татарстан, иных юридических лиц;

б) о распоряжении государственным имуществом, в том числе:

о внесении государственного имущества в качестве вклада в уставный капитал юридического лица;

о передаче некоммерческой организации, учредителем которой является Республика Татарстан, государственного имущества в качестве имущественного взноса;

о передаче государственного имущества в федеральную или муниципальную собственность;

о заключении, изменении, прекращении концессионного соглашения;

в) о принятии имущества в собственность Республики Татарстан;

г) об осуществлении иных мер, направленных на эффективное управление государственным имуществом, в соответствии с законодательством;

8) назначение, выдвижение для избрания, согласование назначения и выдвижения для избрания в случаях, установленных законодательством, представителей государства в органы управления и контроля хозяйственных обществ и товариществ, акции (доли) которых находятся в собственности Республики Татарстан, за исключением акционерных обществ, созданных в процессе приватизации, в отношении которых принято решение об использовании специального права («золотой акции») или о закреплении акций указанных обществ в собственности Республики Татарстан;

9) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям органов исполнительной власти Республики Татарстан в сфере управления и распоряжения государственным имуществом относятся:

1) осуществление от имени Республики Татарстан полномочий собственника государственного имущества;

2) внесение в Кабинет Министров Республики Татарстан предложений о создании, реорганизации, ликвидации государственных учреждений Республики Татарстан, государственных унитарных предприятий Республики Татарстан;

3) осуществление функций и полномочий учредителя государственных учреждений Республики Татарстан;

4) осуществление контроля за сохранностью и целевым использованием государственного имущества;

5) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 6. **Учет государственного имущества**

1. Учет государственного имущества включает в себя получение, экспертизу и хранение документов, содержащих сведения о государственном имуществе, а также внесение указанных сведений в Реестр в объеме, необходимом для осуществления полномочий по управлению и распоряжению государственным имуществом.

2. Учету в Реестре подлежит государственное имущество, составляющее казну Республики Татарстан, а также государственное имущество, закрепленное за государственными унитарными предприятиями Республики Татарстан на праве хозяйственного ведения или на праве оперативного управления и за государственными учреждениями Республики Татарстан на праве оперативного управления.

3. Учет государственного имущества осуществляется уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области земельных и имущественных отношений.

4. Ведение учета государственного имущества в Реестре осуществляется в электронной форме.

5. Положение о Реестре, в том числе виды объектов учета, определяемые в соответствии с федеральным законом, утверждается Кабинетом Министров Республики Татарстан.

6. Внесение в Реестр сведений об объектах учета, внесение изменений в эти сведения, исключение сведений об объектах учета из Реестра осуществляются на основании документов, оформленных в соответствии с законодательством.

7. При ведении учета государственного имущества уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области земельных и имущественных отношений осуществляется контроль достоверности предоставляемых сведений об объектах учета, подлежащих включению в Реестр.

Статья 7. **Управление и распоряжение государственным имуществом**

1. Управление и распоряжение государственным имуществом, в том числе составляющим казну Республики Татарстан, осуществляются после его учета в Реестре.

2. В состав имущества казны Республики Татарстан входят не закрепленные за государственными унитарными предприятиями Республики Татарстан на праве

хозяйственного ведения или на праве оперативного управления и за государственными учреждениями Республики Татарстан на праве оперативного управления объекты движимого и недвижимого имущества, находящиеся в собственности Республики Татарстан.

3. Государственное имущество может передаваться во временное владение и (или) пользование физическим и юридическим лицам, федеральным органам государственной власти и органам местного самоуправления, отчуждаться, в том числе в федеральную и муниципальную собственность, а также в отношении государственного имущества могут совершаться иные сделки в соответствии с федеральными законами, а также принимаемыми в соответствии с ними законами Республики Татарстан.

4. Управление и распоряжение государственным имуществом осуществляются Кабинетом Министров Республики Татарстан, уполномоченными на то иными органами исполнительной власти Республики Татарстан и организациями, а также через представителей Республики Татарстан в органах управления и контроля юридических лиц, созданных Республикой Татарстан и с участием Республики Татарстан.

5. Контроль за сохранностью и целевым использованием государственного имущества осуществляется:

1) в отношении имущества казны Республики Татарстан – уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области земельных и имущественных отношений непосредственно или через специализированные организации;

2) в отношении иного государственного имущества – органами исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченными Кабинетом Министров Республики Татарстан.

### Статья 8. **Признание утратившими силу отдельных законодательных актов (положений законодательных актов) Республики Татарстан**

Признать утратившими силу:

1) Закон Республики Татарстан от 8 апреля 2005 года № 65-ЗРТ «О государственном имуществе Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 4 (I часть);

2) Закон Республики Татарстан от 26 июля 2007 года № 35-ЗРТ «Об управлении и распоряжении государственным имуществом Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 7 (II часть);

3) Закон Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 75-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об управлении и распоряжении государственным имуществом Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 10 (I часть);

4) статью 3 Закона Республики Татарстан от 7 октября 2015 года № 70-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О приватизации государственного имущества Республики Татарстан» и отдельные законодательные

акты Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 10 (I часть);

5) Закон Республики Татарстан от 9 октября 2015 года № 77-ЗРТ «О внесении изменения в статью 8 Закона Республики Татарстан «Об управлении и распоряжении государственным имуществом Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 10 (I часть);

6) статью 1 Закона Республики Татарстан от 9 июля 2016 года № 62-ЗРТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2016, № 7 – 8);

7) статью 7 Закона Республики Татарстан от 11 декабря 2021 года № 89-ЗРТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан и признании утратившими силу отдельных положений законодательных актов Республики Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2021, № 93 (часть I).

Статья 9. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2023 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казань, Кремль
23 декабря 2022 года
№ 96-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне (алга таба – дәүләт мөлкәте) исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Әлеге Законның гамәли көче Татарстан Республикасы милкендәге җир, җир асты байлыклары һәм башка табигый ресурслар, кыйммәтле кәгазьләр (акцияләрдән кала), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары белән идарә итүгә һәм эш итүгә, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруга бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

2 статья. **Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп тору;

3) дәүләт мөлкәте белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне тикшереп тору;

4) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

### 4 статья. Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре

Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү;

2) акцияләре Татарстан Республикасы милкендәге Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия булган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акционер җәмгыятьләр исемлеген раслау;

3) дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итү;

4) акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасы милкендәге хуҗалык итү җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә һәм тикшереп тору органнарына дәүләт вәкилләрен законнарда билгеләнгән очракларда билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү, хосусыйлаштыру барышында төзелгән, үзләренә карата махсус хокуктан («алтын акция») файдалану яисә әлеге җәмгыятьләрнең акцияләрен Татарстан Республикасы милкенә беркетү турында карар кабул ителгән акционер җәмгыятьләрдән тыш;

5) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

### 5 статья. Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре

1. Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) әлеге Закон үтәлеше өчен норматив хокукый актлар бастырып чыгару;

2) дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

3) дәүләт мөлкәте реестры – Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестры (алга таба – Реестр) турындагы нигезләмәне раслау;

4) дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын билгеләү;

5) дәүләт мөлкәте өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибен урнаштыру;

6) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре исемлекләрен раслау;

7) түбәндәге карарларны кабул итү:

а) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләрен, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен, башка юридик затларны төзү турында;

б) дәүләт мөлкәте белән эш итү турында, шул исәптән:

дәүләт мөлкәтен юридик затның устав капиталына кертем сыйфатында кертү турында;

дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы гамәлгә куйган коммерциягә карамаган оешмага мөлкәти взнос сыйфатында тапшыру турында;

дәүләт мөлкәтен федераль яки муниципаль милеккә тапшыру турында;

концессия килешүен төзү, үзгәртү, туктату турында;

в) мөлкәтне Татарстан Республикасы милкенә кабул итү турында;

г) законнар нигезендә дәүләт мөлкәте белән нәтиҗәле идарә итүгә юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашыру турында;

8) акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасы милкендәге хуҗалык итү җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә һәм тикшереп тору органнарына дәүләт вәкилләрен законнарда билгеләнгән очракларда билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү, хосусыйлаштыру барышында төзелгән, үзләренә карата махсус хокуктан («алтын акция») файдалану яисә әлеге җәмгыятьләрнең акцияләрен Татарстан Республикасы милкенә беркетү турында карар кабул ителгән акционер җәмгыятьләрдән тыш;

9) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы исеменнән дәүләт мөлкәте милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен, Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләрен төзү, үзгәртеп кору, бетерү турында тәкъдимнәр кертү;

3) Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

4) дәүләт мөлкәтенең сакланышын һәм максатчан кулланылышын тикшереп тору;

5) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

6 статья. **Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу**

1. Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу дәүләт мөлкәте турында белешмәләр булган документларны алуны, аларга экспертиза ясауны һәм аларны саклауны, шулай ук күрсәтелгән белешмәләрне дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә Реестрга кертүне үз эченә ала.

2. Реестрда Татарстан Республикасы казнасын тәшкил итә торган дәүләт мөлкәте, шулай ук хуҗалык алып бару хокукында яисә оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә һәм оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә беркетелгән дәүләт мөлкәте исәпкә алынырга тиеш.

3. Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла.

4. Реестрда дәүләт мөлкәтен исәпкә алуны башкару электрон рәвештә гамәлгә ашырыла.

5. Реестр турында нигезләмә, шул исәптән федераль закон нигезендә билгеләнә торган исәпкә алу объектлары төрләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

6. Исәпкә алу объектлары турындагы белешмәләрне Реестрга кертү, әлеге белешмәләргә үзгәрешләр кертү, исәпкә алу объектлары турындагы белешмәләрне Реестрдан төшереп калдыру законнар нигезендә рәсмиләштерелгән документларга таянып башкарыла.

7. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан дәүләт мөлкәтен исәпкә алуны башкарганда, Реестрга кертелергә тиешле исәпкә алу объектлары турында белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү**

1. Дәүләт мөлкәте, шул исәптән Татарстан Республикасы казнасын тәшкил итүче дәүләт мөлкәте, белән идарә итү һәм эш итү аны Реестрда исәпкә алганнан соң гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы казна мөлкәте составына хуҗалык алып бару хокукында яисә оператив идарә хокукында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә һәм оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә беркетелмәгән Татарстан Республикасы милкендәге күчемле һәм күчемсез мөлкәт объектлары керә.

3. Дәүләт мөлкәте физик һәм юридик затларга, федераль дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына вакытлыча биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшырылырга, милеккә, шул исәптән федераль һәм муниципаль милеккә, бирелергә мөмкин, шулай ук дәүләт мөлкәтенә карата федераль законнар, шулай ук алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнары белән бүтән гамәлләр башкарыла ала.

4. Дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең моңа вәкаләтле башка органнары һәм оешмалары тарафыннан, шулай ук Татарстан Республикасы тарафыннан һәм Татарстан Республикасы катнашында төзелгән юридик затларның идарә һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы вәкилләре аша башкарыла.

5. Дәүләт мөлкәтенең сакланышын һәм максатчан кулланылышын тикшереп тору түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы казна мөлкәтенә карата – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан турыдан-туры яисә махсуслашкан оешмалар аша;

2) башка дәүләт мөлкәтенә карата – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан.

8 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 2005 елның 8 апрелендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш));

2) «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (II өлеш));

3) «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 10 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш);

4) «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 7 октябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 10 (I өлеш);

5) «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2015 елның 9 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 10 (I өлеш);

6) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 9 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 7 – 8);

7) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 11 декабрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законының 7 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 93 (I өлеш).

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 23 декабрь
№ 96-ТРЗ